وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклапябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

# Дин вә Мәгыйшәт

№22 (139). 1 июнь 2012 / 11-рәҗәп-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Чистай яңалыклары ▷2◁



Сөннәткә утырту ▷3◁

Благотворительный Фонд Закят

"Зәкят" фонды балалар өчен үнкөнлек уздыра ▷4◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

МӨФТИЯТ
ЯҢА КИЛЕШҮ ТӨЗЕДЕ

28 май көнне "Татмедиа" агентлыгында ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан салу станциясе, Рус Православие чиркәвенең Казан епархиясе һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәте арасында массакүләм донорлыкны үстерү өлкәсендә социаль хезмәттәшлек турындагы беркетмәгә кул куелды.

Документны Республика кан салу станциясе баш табибы Рамил Тураев, ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз һәм Татарстан архиепископы Анастасий имзалады. Әлеге рәсми чара ТР Сәламәтлек саклау министры Айрат Фәррахов катнашында узды.

Татарстанда мондый төр килешүгә беренче тапкыр кул куелды. Әлеге килешү кысаларында һәр мәчеттә һәм чиркәүдә кан тапшыру урыннары турында мәгълүматлар язылган элмә такталары куелачак.

**ИСЛАМ МӘГАРИФЕ СОВЕТЫ УТЫРЫШЫ УЗДЫ**

30 май көнне РИУда Ислам мәгарифе советының Бөтенроссия утырышы үткәрелде. Чарада Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз һәм илебезнең барлык ислам вузлары җитәкчеләре катнашты. Утырышта РИУ ректоры, сәясәт фәннәре докторы Рәфыйк Мөхәммәтшин бертавыштан советның яңа рәисе итеп сайланды.

Әлеге чарада рәис сайлаудан тыш башка мәсьәләләр дә каралды. Мәсәлән, ректорлар Россиядә ислам мәгарифе үсеше концепциясен әзерләү турында сүз алып бардылар. Шулай ук ислам илаһияте (теологиясе) буенча укыту программасы турында да фикер алышу булды. Әлеге программа расланган очракта, ул Россиянең барлык ислам вузларына да тәкъдим ителәчәк.

**ТАНЫЛГАН ВӘГЫЙЗЬ КАЗАНГА КИЛӘ**

Мөселман яшьләре берлеге танылган вәгазь укучы Рәшит Исаевның лекцияләренә чакыра. Лекцияләр 2 һәм 3 июнь көннәрендә Казанның Әниләр мәчетендә өйлә намазыннан соң узачак, дип хәбәр итә www.islam-today.ru сайты.

Рәшит Исаев, бигрәк тә яшьләр арасында, Әбу Гали әл-Ашари исеме белән билгеле. Ул Дагстан һәм Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтләре тарафыннан хупланган китаплар авторы, аның дисклары Россия күләмендә меңләгән тираж белән тарала. Әбу Гали шулай ук www.darul-fikr.ru сайтына нигез салучыларның да берсе. Әлеге портал Исламга багышланган иң популяр сайтлар рәтендә.

*Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды*

**ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!**

**2012 елның II яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы – 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу дәвам итә. 6 айга язылу бәясе – 118,38 сум.**

# Мөфти Илдус хәзрәт Фәизнең 1 июнь – Балаларны яклау көне уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

***Мәрхәмәтле вә Рәхимле Аллаһ исеме белән!***
***Әссәламегаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү!***

1 июнь – җәйнең тәүге көне һәм балаларның җәйге каникуллары башланган вакыт. Беренче июньдә дөньяның күп кенә илләрендә Балаларны халыкара яклау көне билгеләп үтелә. Россиядә әлеге бәйрәм шулай ук игътибардан читтә калмый. Бездә Балаларны яклау көне, дәүләтнең һәм җәмгыятьнең яшь буын өчен җаваплылыгын искәртеп, балачакның үтә мөһим проблемаларын һәм аларның шатлык-куанычын гаҗәеп рәвештә үзенә сыйдыра алган дата.

Яшь буынны кайгырту һәр илнең иң әһәмиятле, өстенлеккә ия юнәлеше булып тора. Чөнки яшь буын белән якты һәм имин киләчәккә өмет-ышанычыбыз бәйләнгән. Илебез сабыйлары сау-сәламәт булсын, сыйфатлы белем алсын, спорт һәм иҗат белән шөгыльләнсен, рухи һәм әхлакый үсештә камиллеккә ирешсен өчен кулыбыздан килгәннең барысын да эшләү безнең бурычыбыз.

Балалар үзләренең хокукларын яклауга һәм саклауга мохтаҗ. Ә иң мөһиме – барысының да таянычы һәм тормышта ярдәм кулы сузучылары булса иде.



Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) ассызыклаганча: "Тәкъва булыгыз һәм балалар арасында гаделлек күрсәтегез (бертигез һәм бертөсле кайгыртучанлык һәм игътибар бирегез)!", шулай ук: "Балаңны тәрбияләгәндә әйтелгән һәрбер сүз синең өчен сәдака буларак бара". Пәйгамбәребезнең (сгв) тормышы сөйләнгән китапларда аның балаларга һәм оныкларга булган мәхәббәтеннән бик күп мисаллар табарга мөмкин. Бары тик олы җанлы, мәрхәмәтле кешеләр генә балага киләчәк көнгә ышаныч һәм куркынычсызлык хисен бирә, аларны югары әхлакый кыйммәтләрне аңларга, кешенең кайгысын уртаклашырга, аның хәленә керә белергә, теләктәшлек күрсәтергә һәм яңа биеклекләргә күтәрелергә өйрәтә ала.

Чын күңелемнән балаларыбызның бу җәйне күңелле һәм кызыклы итеп үткәрүләрен теләр идем. Ә безгә – өлкәннәргә, аларның җәйге ял вакытларын имин, файдалы һәм мавыктыргыч итеп уздыру өчен тырышырга кирәк. Республикабызның күп кенә мәчетләрендә июнь аеннан башлап мәктәп яшендәге балалар өчен җәйге лагерьлар башланып китә. Мондый лагерьларның төп максаты – яшь буынга халкыбызның дини, әхлакый тәрбиясен җиткерү. Мөселман лагерьларына җәлеп ителгән балаларга ислам дине нигезләре, дини этика, пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) тормыш юлы, гарәп теле буенча мавыктыргыч сабаклар укыту каралган.

Сезгә һәм балаларыгызга ныклы сәламәтлек, иминлек һәм үзара аңлашып яшәүне телим! Һәр өйдә балаларның шат тавышы яңгырап торсын иде! Һәр гаиләгә Аллаһы Тәгаләнең мәрхәмәте һәм шәфкате ирешсен!

1 ИЮНЬ – БАЛАЛАРНЫ ХАЛЫКАРА ЯКЛАУ КӨНЕ

# БАЛАЛАРЫБЫЗ – МИЛЛӘТЕБЕЗНЕҢ КИЛӘЧӘГЕ



**Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (сгв) балаларга гаять зур мәртәбә һәм әһәмият биргән, үзенең хәдис-шәрифендә ул: "Балаларыгызга кадер-хөрмәт күрсәтегез, аларны асыл кешеләр итеп тәрбияләгез", - дип әйтә. Димәк, пәйгамбәребезнең бу хәдисеннән аңлашылганча, ата-аналар өчен бала тәрбияләү - иң төп, иң изге бурыч булып тора. Ватаныбызның һәм милләтебезнең киләчәге дә аларның дини, милли вә әхлакый яктан яхшы кешеләр булып җитешүләренә бәйләнгән. Шул сәбәпле аларның йөрәкләрен сәламәт, дини һәм милли мәдәниятебезгә бәйле итеп, ватан һәм милләт сөюе белән тулы итеп үстерү - һәр ата-ананың иң беренче вазифасыдыр.**

Ата-ана баласын кыйнамыйча-кызмыйча, сөю һәм шәфкать эчендә үстерергә тиешле. Аларның илаһи әманәт булуларын онытырга тиеш түгелбез.

Балаларыбыз, карау һәм тукландырудан да бигрәк, безнең сөю һәм шәфкатькә мохтаҗдыр. Гаиләләрнең җимерелүе, андагы кимчелекләр сабыйларның җаннарын өшетә, рухларын төшенкелеккә дучар итә. Бала гаилә хозурыннан, ата-ананың сөюеннән һичбер заман туймас. Бу мәсьәләне инкарь итү, бу хакыйкатьне күрмәмешкә салышу төрле хәлләрнең килеп чыгуына юл ачадыр.

Әгәр сабыйлар ата-анасы белән берлектә һәм әби-бабасы янында тәрбияләнсә, бу балалар аларга бәйле булырлар. Ата-ананың сөюен, җылы бер карашын татымаган балалар үсеп җиткәч гаиләсеннән йөз чөерә, уку-һөнәр алу юлында да кимчелекләре була, җәмгыятебез һәм дәүләтебезнең башына бәла китереп чыгара. Һичшиксез, моның өчен иң беренче чиратта ата-ана җаваплыдыр.

Бер мәшһүр акыл иясе болай дигән: "Сабыйлыкта ныклы дини һәм милли тәрбия алмаган кешенең (үсеп җиткәч нинди генә дәрәҗәләргә күтәрелсә дә) шәхсият зәгыйфьлеге күренер".

Пәйгамбәребез (сгв) безгә: "Балаларыбызга кече яшьтән Пәйгамбәрен сөйдерегез", – дип әмер иткән. Игътибар итегез: "Балаларыгызга Пәйгамбәрне белдерегез", – димәгән, ә бәлки "сөйдерегез" дигән. Чөнки бала белгәннән, өйрәнгәннән алда сөю хисен кичерергә тиеш. Ә бу сөю аның яралгысында ук бар. Көндәлеге һәр сөюнең чишмә башы да Аллаһны һәм Пәйгамбәрне сөюдер. Әмма моның өчен балага башта ата-анасының Аллаһны, Пәйгамбәрне сөюен, аңа итагать итүен һәрвакыт күрсәтергә кирәк. Ата-ана Аллаһның кушканнарына һәм тыйганнарына игътибарлы булмаса, үз диненә, теленә, исеменә хөрмәт күрсәтмәсә, бала Аллаһның барлыгын һәм берлеген ничек таныр?

Пәйгамбәребез, моннан тыш, җиде яшендә балага намаз өйрәтә башлауны әмер иткән. Ә инде намаз укымаган тәкъдирдә, ун яшьтән соң шелтәләп, мәҗбүри рәвештә укытырга кушкан. Бала пөхтәлекне – госел-тәһарәтне, намаз-уразаны, яхшыны һәм яманны, хәләл вә хәрәмне бәлигъ булганчыга кадәр белергә тиеш.

Гаиләбезнең, үзебезнең һәм милләтебезнең киләчәген тәэмин итәчәк балаларыбыз никадәр горур холыклы, сәламәт һәм саф рухлы үстерелсә, киләчәгебезгә дә шулкадәр өмет белән карау мөмкин булачак.

***(Ахыры 4 нче биттә.)***

# ЧИСТАЙ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

**27 май көнне Чистай шәһәрендәге Әнәс мәчетенең өч яшьлек туган көне билгеләп үтелде. Әлеге чарада мәчет төзелешенә үзеннән зур өлеш керткән Әхмәтҗанов Тәлгат Әнәс улы да катнашты, ул мәчет янындагы спорт мәйданчыгында ярышлар оештырды.**

Бәйрәм Әнәс мәчете имамы Әбубәкер хәзрәт тарафыннан Коръән уку белән башланып китте, Чистай шәһәре имам-мөхтәсибе Алмаз хәзрәт дога кылды. Килгән кунакларга, оештыручыларга зур рәхмәт белдерелде.





Чарада ТР Дәүләт Советы депутаты Фәрит Мифтахов, ТР мөселманнары Диния нәзарәте вәкилләре – Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Габдулла хәзрәт Әдһәмов, мөфтиятнең гомуми бүлек мөдире Ильяс хәзрәт Җиһаншин, яшьләр бүлегеннән Рафаэль хәзрәт Мифтахов, Чистай районы хакимияте башлыгы Илдус Әхмәтҗанов һәм РИУ мөгаллимнәре – ислам хокукы кафедрасы мөдире Мөхәммәтморат Моратов белән ислам фәннәре факультеты деканы Рамазан Курамшин катнашты.

Спорт ярышларына килгәндә исә, бер футбол буенча гына да 13 команда көч сынашты. Беренче урынны Чистайның Әнәс мәчете командасы, икенче урынны – Түбән Кама футболчылары яуласа, өченчедә – Чистай мөхтәсибәтенең "Иман" командасы. Барлык катнашучыларга да кыйммәтле бүләкләр, дипломнар тапшырылды.

Ярышлар тәмамланганнан соң, зиратка Мөхәммәдзакир хәзрәт Чистави каберенә барып, дога кылынды.

* * *

Узган атнаны Чистай мөхтәсибәтенә караган Икенче таш мәчеттә мөселман балалары өчен дини кануннар нигезендә тәрбия бирә торган мөселман балалар бакчасы ачылды. "Бүгенге көндә балаларыбызга яшьтән үк дини тәрбия бирү, аларны дини кануннар нигезендә тәрбияләү буенча зур эшләр башланды. Чистайда мөселман балалар бакчасы булдыру бик тә мөһим мәсьәлә. Бу ниятне тормышка ашыру өчен иң күп хезмәт куючы – Чистай имам-мөхтәсибенең беренче ярдәмчесе, Икенче таш мәчет имам-хатыйбы Мөнир хәзрәт Сөләйманов. Балалар бакчасының эшчәнлеге гадәти бакчадан хәләл ризык булуы, балаларга дини-әхлакый тәрбия бирелүе белән аерылып тора. Бүгенге көндә мөселман балалар бакчасы үз эшчәнлеген әти-әниләрнең ай саен түләнә торган түләүләре һәм дә мөхтәсибәтнең матди ярдәме белән алып бара. Чистай халкы шәһәребездә мөселман балалар бакчасы ачылуга карата зур рәхмәтен белдерде", – дип хәбәр иттеләр район мөхтәсибәтеннән. Әти-әниләрнең сүзләренә караганда, мондый балалар бакчалары күбрәк булган булса, безнең арабызда җинаятьчеләр, закон бозучылар, кешеләргә зарар китереп, төрмәләргә эләгүчеләр күпкә азрак булыр иде. Чистай мөхтәсибәте исеменнән "Иң хәерле изге эш" дигән рәхмәт хаты Мөнир хазрәткә тапшырылды. Раббыбыз бу эшләрне дәвамлы кылса иде.

* * *

Күптән түгел генә районның Нур мәчетендә хәйрия ашы уздырылды. Анда кырыкка якын кыз һәм егет – нигездә шәһәрнең 7 нче мәктәп укучылары чакырылды, дип хәбәр итә "Чистай хәбәрләре" газетасы.

– Бүген яшьләрне дини-әхлакый тәрбияләү мәсьәләсе аеруча кискен тора, кайбер дини кыйммәтләр юкка чыкты, идеаллар югалды, – дип белдерде Икътисад, идарә һәм хокук институтының Чистай филиалы директоры Ольга Добронравова. – Мәчеттә шундый әңгәмәләр уздыру аеруча кирәк. Без күпмилләтле республикада яшибез, янәшәбездә татарлар, руслар, чувашлар, азәрбайҗаннар, мордвалар һ. б. гомер сөрә, кечкенәдән үк дини хисләргә, традицияләргә, бер-беребезнең мәдәни гадәтләренә кызыксыну тәрбияләргә кирәк. Сине санласыннар дисәң, үзең дә әти-әниеңә, өлкәннәргә, әйләнә-тирәдәгеләргә хөрмәт белән карарга өйрән.

Яшь кунаклар арасында төрле диндәге кешеләр бар иде, һәр дин шәфкатьлелек күрсәтүгә, әхлакый сафлыкка, үзең һәм башкалар белән килешеп яшәргә чакыра. Дин, ышану игелеккә хезмәт итә. Нур мәчетенең гасырдан артык тарихы бар, һәм ул һәрвакытта да кешеләр күңеленә яктылык, тынычлык алып килә.

Әхлакый халәт, мәңгелек кыйммәтләр турындагы сөйләшүдә Чистай шәһәренең муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары Михаил Ксенофонтов та катнашты. Мәдрәсә бинасында бәйрәм ашыннан соң сүз диалог формасында дәвам итте. Җанланып киткән балалар ислам тарихы, дини кануннар, мәдрәсәдәге дәресләр турында сораулар бирде.

**Мәгълүматлар Чистай мөхтәсибәте белән берлектә әзерләнде**

## Алабугада мөселман Сабантуе узды

***27 май көнне Алабуга мөхтәсибәте шәһәрнең "Лесная сказка" лагеренда мөселман Сабантуе оештырды. Әлеге чараның максаты – мөселман өммәтен берләштерү, туплау, аларны табигатькә алып чыгып ял иттерүдән гыйбарәт иде. Сабантуйда 300 дән артык кеше катнашты. Барлык бәйге-уеннарны Алабуга Җәмигъ мәчете коллективы һәм мәчеткә йөрүче мөселман кардәшләребез үткәрде.***

Бәйрәм Коръән уку белән башланып китте, аннан соң Габделвәли хәзрәт Климов тарафыннан вәгазь сөйләнде. "Сабан туе – чорлар аша безнең көннәргә кадәр килеп җиткән халкыбызның матур бәйрәме, аның нигезендә татарның бай мирасы, йолалары ята. Иң яхшы гореф-гадәтләребез ислам диненнән үсеп чыккан", – дип белдерде Алабуга мөхтәсибе Әҗмәл хәзрәт Саматов.

Алабуга Җәмигъ мәчете имам-хатыйбы Азат хәзрәт Шәрипов үзенең вәгазендә мөселманнарның урта, гадел өммәт икәнен искә төшерде. "Мөселман кешесе Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылыр өчен яратылганын һәрвакыт истә тота, шулай ук ул дөнья эшләрен дә алып бара, вакытында күркәм итеп ял да итә белә, бүген монда җыелышубыз югарыда әйтелгәннәргә яхшы дәлил", – дип ассызыклады ул.

Спорт уеннарыннан аеруча зур игътибар милли көрәшкә, кул көрәшенә, уктан атуга бирелде. Моннан тыш, хатын-кызлар су ташу, кашыкка йомырка салып йөгерү кебек уеннарда катнашты. Яшьләр авыш колгада йөрү буенча зирәклеген күрсәтте. Сабантуйның икенче өлеше күңел ачу чаралары белән үрелеп барды. Көрәштә җиңеп батыр калучыга сарык бирелде.

Алабуга шәһәре башкарма комитеты ул көнне бәйрәм чараларында катнашу өчен халыкка түләүсез транспорт булдырды. Янә шәһәр җитәкчелегенең һәм иганәчеләрнең ярдәме белән бәйгеләрдә һәм уеннарда җиңүчеләргә дә бүләкләр әзерләнде. Бу чарага мөселманнар гаиләләре белән килгән иде, шуна күрә уеннарда бик күп балалар катнашты һәм аларның һәрберсенә бүләкләр бирелде. Сабантуйны башыннан алып ахырына кадәр бик матур һәм үтемле итеп Алабуганың Җәмигъ мәчет мөгаллиме Ислам хәзрәт Гөлҗанов алып барды.

Табигать куенында узган әлеге бәйрәмдә ял итү өчен барлык шартлар да тудырылган иде. Ашау-эчү, сәүдә тулы куәтенә барды. Барыннан да бигрәк, Сабантуе балалар өчен зур бәйрәм булды.

Әлеге милли бәйрәмебездә ике гаилә гакыйкә корбаны чалып мәҗлес оештырды. Бәйрәмдә шулай ук Кама алды төбәге казые Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев, Тукай районы имам-мөхтәсибе Җәүдәт хәзрәт Харрасов та катнашты.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв): "Аллаһ каршында көчле көчсездән сөйкемлерәк, әмма ләкин боларның икесе дә хәерле", – дигән. Чарада район мөхтәсибе Әҗмәл хәзрәт бәйрәмдә катнашучыларны шулай ук Рәҗәп ае, Коръән елы турында да таныштырды.

Исегезгә төшерәбез: Алабугада мөселманнар Сабантуе быел сигезенче мәртәбә узды. Мондый төрдәге Сабантуй оештыру Рөстәм хәзрәт Ясәвиев тәкъдиме белән башланган иде. Шулай итеп, милли ярыш елданел колачлырак уза барды. Сигез ел дәверендә аны хәтта чит төбәкләрдән дә килеп тамаша кылдылар.

**P.S.: Алабуга Җәмигъ мәчете яшьләр белән эшләүгә дә зур игътибар биреп килә. Мәчетнең подвалында тренажер, уен заллары, балалар өчен көрәш түгәрәкләре эшли.**

**Нияз САБИРҖАНОВ**

## "Сабыйга" акциясе хөкем ителгән мөселманнарны да җәлеп итте

***ТР мөселманнары Диния нәзарәте, "Болгар" радиосы һәм Бөгелмә районы мөхтәсибәте белән берлектә, 2012 елның апрель-май айларында Бөгелмә шәһәрендәге әти-әниләре ташлаган ятим сабыйлар өчен подгузник, пеленка кебек кирәк-яраклар җыю максатыннан "Сабыйга" хәйрия акциясен оештырган иде.***

30 майда ТР мөселманнары Диния нәзарәте вәкилләре Бөгелмә районы үзәк хастаханәсендә әлеге акциягә йомгак ясап кайтты.

"Бөгелмә шәһәрендәге район үзәк хастаханәсе табибы шәхсән үзе каршы алды, хастаханә белән таныштырды. Хастаханә җитәкчелегенә акция кысаларында җыелган кирәк-ярakларны тапшырдык. Әлеге акциягә Казан шәһәрендәге 18 нче Төзәтү колониясендәге ирекләреннән мәхрүм ителгән мөселман кардәшләребез дә кушылды. Аларның бергәләшеп җыйган хәер акчасына балалар өчен электр плитәсе алдык. Әлеге акция, бер яктан, республикабыз халкының мәрхәмәтле, олы йөрәкле булуын дәлилләсә, икенчедән, ирektән мәхрүм ителгән кардәшләребезнең шушылай ярдәм кулы сузулары – моңарчы күзәтелмәгән сөенечле хәл булды", – дип билгеләп үтте ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлеге җитәкчесе Гөлнара Садыйкова.

# БАЛАЛАРЫБЫЗ — МИЛЛӘТЕБЕЗНЕҢ КИЛӘЧӘГЕ

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

Ата-ананың балаларына хәрәм ризык ашатырга да хакы юк. Без моңа бик нык игътибар итәргә тиешле. Чөнки начар орлыктан зәгыйфь башак, начар уңыш алырбыз. Шул сәбәпле бала ана карынынnan төшкәнчегә кадәр, нәселнең бозылуы мөмкин.

Хәрәм ризык һәм алкогольле эчемлекләр нәселнең бозылуына китерүче сәбәпләр. Соңыннан Аллаһы Тәгалә бу балага хәрәм ашаткан ата-ананың башына бәла китерер.

Тагы да балага дөньясы һәм ахирәте хакындагы белемнәрне өйрәтү, аны бер һөнәр иясе итү тиешле. Хәләл юл белән мал казанырга өйрәткәннән соң, аларны тиешле вакытында өйләндерү, начар юлга басмауларына игътибар итү сорала.

Аларның үзенчәлекле рухи һәм мәгънәви тәрбияләренә нык игътибар итәргә бурычлыбыз. Аларны тормышка яхшы итеп әзерләсәк, гомер кичергәндә безне төрле авырлыкларга төшермәсләр.

Бу уңайдан Пәйгамбәребез (сгв) дә балаларга дәверегезнең спорт төрләрен өйрәтегез, дигән. Онытмыйк: яшьлекне бушка үткәрү картлыкта үкенечләргә, төрле уңайсызлыкларга китерәдер. Балаларыбызның, яшьләребезнең һәм милләтебезнең киләчәген һәлакәттән саклау безнең бурычыбыз.

Динебездә бала тәрбиясенең асыл максаты – үз дәүләтенә, туган җиренә, гаиләсенә, гомумкешелек дөньясына бер файдалы кеше әзерләүдән гыйбарәттер. Бу максатларга ирешү өчен бала кече яшьтән үк төрле һөнәрләргә өйрәнергә вә сәнгать сәхибе булырга, шуңа омтылырга тиеш.

Имам Газәли хәзрәтләре бала тәрбиясе хакындагы әсәрендә түбәндәгеләрне язган: "Бала – ата-ана кулындагы бер әманәттер, бөек бер нигъмәттер. Шул нигъмәтнең кыйммәте беленмәсә, ул кулдан китәр. Бала – ул шәм кебек төрле сурәтләргә керер. Бала – ул таза бер туфрак кебек. Шул таза туфракка нинди орлык чәчелсә, аның җимеше дә шулай хасил булыр. Сабыйларыбызга иман, Коръәни-Кәрим һәм Аллаһы Тәгаләнең әмерләрен өйрәтеп, ахирәт һәм дөнья сәгадәтенә кавышырга ярдәмче булырга тиешлебез".

Бу сөю-сәгадәтнең, бу бәхетнең савабы да ата-аналары белән уртак булыр. Ата-аналар өчен балаларын тәрбияләү җәһәннәм утыннан саклану, дөнья газапларыннан саклanудан да мөһимдер.

Әманәт итеп Аллаһы Тәгаләдән тапшырылган үз балаларыбызны ислам дине кушканча тәрбиялик. Балаларыбызның бәхете гаиләдә икәнлеген онытмыйк!

Раббыбыз, һәркайсыбызга да һидаят биреп, әманәтләребезне саклаучы итсә иде. Әссәламегаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү!

**Руслан хәзрәт МОРТАЗИН,**
**Татарстанның төньяк-көнчыгыш төбәге казые**

# ТӨРКИЯДӘГЕ ТАТАР АВЫЛЫ ЯҢА МӘЧЕТЛЕ БУЛДЫ




**Күптән түгел генә Биектау районы имам-мөхтәсибе Тәлгат хәзрәт Гайфуллин, Диния нәзарәте вәкиле буларак, Төркиядә булып кайтты. Тәлгат хәзрәт белән Төркиядәге татар авылы тормышы турындагы әңгәмәне тәкъдим итәбез.**

***– Тәлгать хәзрәт, сезнең Төркия белән күптәннән таныш икәнлегегезне беләбез, ә бу юлы сәфәргә чыгып китәргә нәрсә сәбәп булды?***

– Беренчедән, Төркиядә узган айны Халыкара гарәп теле бәйгесе узды. 20 май көнне Истанбулда бәйгенең җиңүчеләрен котлау тантанасында Россиядән дини вәкил буларак катнаштым. Әйтергә кирәк, бу бәйге бик югары дәрәҗәдә узды: катнашучылар гарәп теле грамматикасы, лексикасы белән генә чикләнеп калмыйча, гарәп телендә театраль тамаша, шигъри һәм чәчмә әсәрләр укуда да көчләрен сынашты. Икенчедән, Төркиядә яшәүче милләттәшләребез Измир, Маниса шәһәрләреннән ерак түгел Гүрсу авылында яңа мәчет салган. Шул мәчетнең ачылу тантанасында Татарстаннан дин әһелләренең дә килүен теләп, мөфтиебезгә хат язганнар һәм миңа шушы тантанада катнашу насыйп булды.

***– Төркиядә сезнең килүегезне ничек кабул иттеләр?***



– Төркия халкының бик тә кунакчыл, киң күңелле икәнлеген бу илдә булып кайткан һәр кеше дә белә торгандыр. Безне дә бик җылы каршы алдылар, Истанбулның күренекле урыннарын, музей, мәчетләрен күрсәтеп, аларның тарихын сөйләделәр, милли ризыклары белән сыйлап кунак иттеләр. Ә татар авылына килгәндә, гомумән, күптән күрешмәгән туганнарын күргән кебек шатландылар.

– Без – татарлар – бөтен дөнья буйлап сибелгән халык. Бүгенге көндә төрле вакытта, төрле сәбәпләр аркасында туган йортларыннан чыгып китеп чит илләрдә тормыш итүче татарлар турында ишетеп беләбез. Сез барган авылга татарлар кайчан барып урнашкан, алар ничек дөнья күрәләр, туган якларын сагыналармы, аларның тормышы безнекеннән нәрсәсе белән аерыла?

– Тукай заманында ук бәхет эзләп чыгып киткән һәм чит илдә берничә нәсел гомер иткән татарлар белән танышу бәхетенә ирештем. Мондагы татарлар бик эшчән, динле. Алар бакчаларында виноград үстереп, аны җыеп алып киптерәләр, шул йөземне саталар, шул рәвешле көн күрәләр. Биредә бүгенге көндә 150 ләп татар кешесе яши. Шуның 70 е – ир–атлар һәм алар бер генә җомганы да калдырмый мәчеткә йөри. Гүрсу авылыннан чыккан 6 татар имамы Төркиянең төрле мәчетләрендә эшли. Район үзәге Алашәһәрдәге иң зур мәчетнең имамы һәм мөәзине дә татар кешесе икән. Төркиягә хас бер үзенчәлек бар: имамнар, мөәзиннәр Коръән хафиз булсалар гына дини хезмәткә алыналар, димәк, мәчетләрдә эшләүче татар имамнары да Коръән хафизлар. Татарстандагы татар авылларында, хәтта шәһәрләрдә андый имам ничәү икән? Уйландыра торган мисал түгелме соң бу?..

***– Чыннан да, уйланырлык хәл бит бу. Безнең чит илдәге милләттәшләребез Коръән ятлап, ислам динен таратып, милләтен үстереп, төрки халык арасында хөрмәткә ирешеп татар халкының данын яклый.***

– Алар татар моңы белән әйтелгән азаннан, Коръән укудан бик хисләнделәр,татарча вәгазь сөйләгәндә өлкәнрәк ир–атларның күзләрендә яшь бөртекләре ялтыраганын күрдем. Бәлки, алар татар сөйләмен ишеткәч, монда күчеп килгән әти–әниләрен искә алганнардыр... Ә мондагы татар диаспорасы тарихын яхшырак аңлау өчен, сезгә, шушы җирлектә туып үскән, милләт өчен янып–көеп яшәүче Бахзат Акташ әфәнденең хатын тапшырам (хатны татар әдәби теленә яраклаштырырга тырыштык): "1890 елларда Татарстандагы Бөгелмә районының Өби авылы һәм аның янәшәсендәге төрле авыллар дини гыйлем, бәхет эзләп, туган җирне ташлап, Төркиядә Күтаһә вилаятенең (районы) Әфәнде Күпресе авылына килеп урнашканнар. Дистәләрчә татар кешесеннән бер төркем (60 лап кеше) милләттәшебез бу авылда йорт салырга җир җитмәү сәбәпле,1954 елда җәмәгать белән хәзерге вакытта Маниса вилаятенә караган Алашәһәр бистәсеннән 10 км ераклыкта яңа бер татар авылы оештыралар. Килгән елларда ук мәчет салалар, әмма бу мәчет еллар узу белән бик нык таушала, бу авылның ихтыяҗларын канәгатьләндерми башлый һәм аны төзекләндерү, яңарту мөмкинчелеге дә булмый. Шул сәбәпле 2010 елның март аенда авыл халкы белән җыелып, бу мәчетне сүтеп, яңа мәчет төзи башладылар. Үз тырышлыгы, үз малы белән Гүрсу авылы татарлары ике елда яңа мәчетне төзеп бетерде. Мәчетне ачу мәҗлесендә без – Төркиядә яшәүче милләттәшләребез – әби–бабаларыбызның, ана телебезнең туган ягы – Татар иленнән дин әһелләренең катнашуын теләдек. Аллаһның рәхмәте, Татарстанның Биектау районы имам–мөхтәсибе Тәлгат хәзрәт Гайфуллин безнең чакыруыбызга җавап биреп, безгә туган телебездә вәгазь сөйләп, татар моңы белән Коръән укып шатландырды. Аңа Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте һәм ризалыгы булса иде!"

***Әңгәмәдәш - Лилия САФИНА***

Медиклар үткәргән тикшеренүләр сөннәтләүнең гигиена саклауда мөһим роль уйнавын дәлилләделәр. Шул сәбәпле яһүди яки мөселман булмаган күп кенә кешеләр дә балаларын кечкенә чакларында ук сөннәткә утырталар. Сөннәтләү – АКШта бүгенге көндә иң киң таралган операция, аны яңа туган ир балаларның 80 процентына ясыйлар. Израильдә бу сан 98 процентка җитә. Бу операцияне андрология буенча махсуслашкан хирурглар ясый.

### Пәйгамбәрләр һәм рәсүлләрнең күрсәтмәсе

Туган көнне исәпкә алмыйча, җиденче көндә сөннәткә утырту – Аллаһ илчесенең күрсәтмәсе.

Мөселманнарга ир баланы туганнан соң нәкъ менә җиденче көндә сөннәтләү мөһим. Хәдистә болай диелә: "Пәйгамбәребез Мөхәммәт (сгв) оныклары Хәсән һәм Хөсәенне туганнан соң җиденче көндә сөннәткә утыртты" (Раваху Табарани).

Балигъ булу белән сөннәтле булу мөселман кешесенең бурычына әйләнә.

Яһүд динендә сөннәтләүгә аерым мәгънә бирелә. Яһүдиләр пәйгамбәрләре боерыгын төгәл үтиләр һәм балаларын туганнан соң сигезенче көндә сөннәтлиләр.

Бу операцияне кичектергән очракта ата–ана төрле проблемалар белән очраша. Бала үскән саен, аңа операцияне кичерүе кыенрак. Әгәр дә ир балага берничә яшь тулып киткән икән, әти–әнисе аңа бу операциянең ничек башкарылуы турында аңлатырга мәҗбүр була. Малайларын операциягә әзерләр өчен төрле "әкият"ләр уйлап чыгаралар. Ләкин бала өчен бу барыбер психологик стресс була. Сабый чактан ук сөннәткә утыртылган бала үзен туганда ук шулай булган кебек кабул итә. Үз–үзен яхшы белештергән яшьтә сөннәтләнгән бала исә, шок хәлендә кала, операцияне авыр кичерә, һәм аңарда куркулар барлыкка килергә мөмкин. Баланың психикасын сакласак, яхшырак булмасмы?

# Сөннәткә утырту

**Сөннәткә утырту фәнни телдә циркумизация дип атала. Бүгенге көндә төрле хирурглар тәкъдим иткән берничә төр циркумизация ысулы бар.**



### Ни өчен балаларны сөннәткә утырталар?

Статистика буенча, яхшы эшләнелгән сөннәтләү операциясе түбәндә язылганнарга булышлык күрсәтә:

– сидек юлында ялкынсыну барлыкка килү ихтималын киметә;

– венерик авырулар, шул исәптән ВИЧ йоктыру ихтималын киметә;

– җенси әгъзаларда рак авыруы барлыкка килү ихтималын киметә;

– пациент хатынының аналык муентыгында рак авыруы барлыкка килү ихтималын киметә.

Балаларда циркумцизиягә төп күрсәткеч булып фимоз (элпә–капчыкның йомылуы), аңа бәйле рәвештә барлыкка килгән ялкынсыну күренешләре, төрле җөйләр, яра урыннары тора. Эш шунда ки, фимоз белән авырганда ябык элпә–капчык эрен, череп таркалучы аксымнарны (смегманы) җыеп тора. Ул матдәләр сидек юлында да төзәлми торган ялкынсыну барлыкка китерәләр.

Өлкәннәрдә операция шулай ук фимоз булганда ясала, ләкин инде бу очракта көтәргә ярамый, тиз ясарга кирәк.

Элпә–капчык хатын–кызлар өчен зарарлы – смегманың аналык муентыгына эләгеп, онкологик шеш үсүгә китерүе расланган. Мөселман һәм яһүд хатыннарының аналык муентыгында рак бик сирәк очрый, чөнки сөннәтле ир–атлардан рак сәбәбе булган кешенең 16 нчы һәм 18 нче тип папилломасын эләктерү ихтималы бик аз.

Хәзерге вакытта Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы ВИЧ–инфекция киң таралган илләрдә яшәүче ир–атларга циркумцизия операциясен ясатырга тәкъдим итә. Оешманың мондый сәясәте Үзәк Африкада үткәрелгән тикшеренүләргә нигезләнеп алып барыла. Бу тикшеренүләр сөннәтле булучыларда ВИЧ йоктыру ихтималы кимүен күрсәтә.

***Нияз САБИРҖАНОВ***

# Дин әһелләренең гыйлемен күтәрү – халыкка хөрмәт күрсәтү

**Казанда, имамнарның белемен ныгыту һәм күтәрү максатыннан, курслар оештыру - ул нәзарәтнең авылларда эшләүче дин әһелләренә игътибары да, халкыбызга карата хөрмәте дә. Чөнки авылда яшәүче имамнарның гыйлемле булуы иң беренче чиратта менә шул халык өчен кирәк. РИУ каршындагы Дин әһелләренең белемен күтәрү үзәгендә ун көн гыйлем туплаган Чүпрәле дин әһелләре 24 майда дипломнар алганда бер-бер артлы әнә шул фикерне кабатлады.**

"Курсларны оештыруның файдасы нидә?" – дип кызыксынгач, Зур Чынлы авылы имамы Габделбари абый Таһиров болай диде: "Укуны бик әйбәт оештырганнар. Бу авыл имамнары өчен белемнәрен күтәрергә дә, бер–берсе белән танышырга, Казандагы хәзрәтләр белән сөйләшергә, сорауларга җавап табарга да бик әйбәт булды.



Киләчәктә дә шушылай укытуларны алып барсыннар. Белем туплау безгә авылларда динне алып баруга зур ярдәм. Төрле авылларда бераз үзгәлекләр бар, менә монда шул сорауларга җавап таптык. Кайсы авылга, мәчеткә керсәк тә, хәзер бер–беребездән аерылып тору булмас, халык та аптырашта калмас, Аллаһ боерса. Менә ул авылда болай, тегесендә тегеләй дигән сүзләр дә бетәр".

Каракитә авылы имамы Фәрдәр Хөсәенов та якташы сүзләрен куәтләде. "Укуларны оештыру безнең өчен генә түгел, халкыбызга, милләтебезгә булган бик олы хөрмәт. Бездән, авылларда яшәүче имамнардан күп сорыйлар, хәзерге буын күп белергә тырыша, картлар да читтә тормый. Коммунистлар режимы вакытында динебез югалып торды. Вәгазь–нәсыйхәт бирүче калмады. Бик күп рухи хәзинәне, мәгърифәтне югалттык. Белемле имамнар, вәгазь сөйләүчеләр, олуг галимнәребез мирас итеп калдырган китапларыбыз булмаса, без белемне беркайдан да туплый алмыйбыз. Күктән иңми, чөнки без илаһи гыйлем ирешүче пәйгамбәрләр дә, әүлияләр дә түгел.

***(Ахыры 4 нче биттә.)***

# "Зәкят" фонды балалар өчен ункөнлек уздыра

**1 июнь - Балаларны халыкара яклау көне буларак күп кенә илләр тарафыннан билгеләп үтелә. Ислам диненең шушы мәсьәләгә карашына килгәндә, аның мәгънәсе күпкә тирәнрәк. Ул авыру балаларны яклау рәвешендә кабул ителсә тагын да хәерлерәк булыр.**

Динебездә балаларны яклау нарасый дөньяга аваз салганнан соң ук башлана дисәк тә ялгышмабыз, чөнки Коръәндә: "Ий мөэминнәр! Үзегезне һәм гаиләгезне, ягъни хатыныгызны һәм балаларыгызны җәһәннәм утыннан саклый күрегез", – дип мөрәҗәгать ителә. "Җәһәннәм утыннан саклау"ның мәгънәсе бик тә тирән, чөнки ул балаларыбызны тәрбия кылганда аларны төрле начар гадәтләрдән һәм гөнаһлардан, төрле әшәкелекләрдән сакларга тырышып үстерүгә барып тоташа. Мөселман кешесе баласын тәрбияләгән вакытта аның тәненә, киеменә генә игътибар бирмичә, беренче булып аның калебен тәрбияли, баланың күңелендә иман булсын, Аллаһны ярату, әти–әнигә тирән ихтирам булсын, дип тәрбияләргә тырыша. Хәзрәти Гомәр (рг) хәлиф булган вакытта аңа әтиле–уллы ике кеше килә дә, әтисе баласы өстеннән хәзрәткә шикаять белдерә башлый: "Я, хәлиф! Балам мине тыңламый, минем белән үзен бик тә тупас, тәкәббер тота, нәрсә эшләп карарга соң?" – дип сорау биргәч, хәзрәти Гомәр (рг): "Малаең белән сөйләшеп алыйм әле", – ди. Шуннан соң малае белән сөйләшеп ала: "Син, олан, нәрсә өчен әти–әниеңне тыңламыйсың? – ди. – Синең алар алдында бурычларың бар бит". Малай исә үз чиратында сорау бирә: "Я, хәлиф, – ди. – Ә аларның минем каршыда бурычлары бармы?" Хәзрәти Гомәр: "Бар", – ди. "Нindиләр? Санап уза алмассызмы аларны?", – ди малай. "Әти кеше үзенең баларына яхшы әни сайларга тиеш. Икенчесе – бала тугач аңа күркәм һәм дә мәгънәле исем кушу мәслихәт. Аннан соң Коръәнне укырга өйрәтеп, Коръән тәрбиясе бирергә тиеш", – дип җавап кайтаргач, бала аңа, үз чиратында, яңа шикаятен белгертә: "Минем әтием мөселман кызына өйләнмәгән (минем әнием мәҗүси – утка табынучы), исемгә килгәндә дә, матур исем бирмәгәннәр – Җүәл – Кара таракан дип кушканнар, Коръән тәрбиясе бирәсе урынга, миңа берни дә бирмәгәннәр, мин Коръәннән бер хәреф тә белмим", – ди. Шуннан соң хәзрәти Гомәр (рг) малайның әтисенә: "Син балаң өстеңдәге үз бурычларны үтәмәгәнсең, хәзер аннан үзеңә карата нәрсә таләп итмәкче буласың", – дип җавап бирә.

Балаларны яклау–саклау турында сөйләшкәнче, иң әүвәл балага нәрсә булса да бирергә кирәк (дөрес, баланың әти–әнисе каршында булган хаклары да бар). Балага изгелек рәвешендә калебенә салырга кирәк, тәрбия биргәннән соң аннан нәрсә булса да көтәргә була. Әти–әнинең, әлбәттә, иң бәхетле мизгелләре шулдыр – кайчан ул баласы турында яхшы сүз–хәбәр ишетә. Әти–әнинең кәефен иң нык боза торган нәрсә – баласы хакында авыр сүз ишетү, шуңа күрә без балаларыбызны әйләнә–тирәбездә булган гөнаһтан, әшәкелекләрдән диндә булган хәлебездә саклау мөһим. 1 июньдә генә түгел, һәр көн, һәр сәгать мөселман кешесе бу хакта уйланырга тиешле. Балаларыбыз өчен барыбыз да Аллаһ каршында җавап тотачакбыз.

"Зәкят" хәйрия фонды 1–10 июнь көннәрендә – Балаларны халыкара яклау көне кысаларында ункөнлек уздырачак. Безнең фондка мөрәҗәгать итүчеләр арасында авыру, инвалид балалар да шактый. Ул балаларны дәвалау өчен йөзәр мең, хәтта миллионлаган сум чыгымнар таләп ителә. Күрәсең, безнең әле моңа көчебез җитеп бетми. Шунлыктан, без кечкенә адымнар белән, пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) әйткәнчә: "Аллаһ каршында иң сөекле гамәл – аз булса да дәвамлы булган гамәл" дигәненә тугры калып, без шундый инвалид балаларның хәлләре аз гына булса да җиңеләйсен, балалар бераз сөенсен, күп балалы гаиләләр ярдәм алсын дип, әлхәмделилләһ, көндәлек эшебезне алып барабыз. 1 июнь уңае белән узачак ункөнлектә хәлләре авыр булган балаларга һәм акчалата, һәм ризыклата ярдәм кабул итүне оештырачакбыз. Финанс ярдәме күрсәтергә теләүчеләр акчаларын безнең фондка түбәндәге реквизитлар аша юллый ала:

Благотворительный Фонд Закят

Расчетные счета:

**ИНН/КПП 1655068682 / 165501001**

**ОГРН 1091600003153 ОКПО 63107012**

**Р/с: 40703810400020000071 в ОАО "Ак Барс" банк г. Казань, ул. Декабристов, д. 1.**

**К/с: 30101810000000000805**

**БИК: 049205805**

**Назначение платежа: благотворительность (указать обязательно!)**

**Адрес: 420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт.**

**Телефоннар: +7 (843) 236–46–32, 264–60–08.**

**Электрон почта: fondzakyat@yandex.ru.**


**Фондның сайты: www.закят.рф.**

**Рөстәм хәзрәт ЯСӘВИЕВ,**

**ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең "Зәкят" хәйрия фонды җитәкчесе**

# *Шәүкәт БИКТИМЕРОВ арабыздан китте*

***28 май көнне РСФСРның халык артисты, Россиянең К.С. Станиславский исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, татар театры легендасы Биктимеров Шәүкәт Хәсән улы фани дөньядан бакый дөньяга күчте.***



"Шәүкәт Биктимеровның арабыздан китүе – татар театры өчен генә түгел, бөтен татар халкы, милләтебез өчен зур югалту. Шәүкәт ага татар халкының милли сәнгате үсешенә бәһасез өлеш керткән олуг шәхесләребезнең берсе иде. Һәрбарчабызның да күңеленә җор күңелле, ихлас, милләт өчен җан атып яшәүче шәхес буларак кереп калды, үзенең тыйнаклыгы һәм сабырлыгы белән күпләргә үрнәк була белде.

Татарстан мөселманнары Дини нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән мәрхүмнең якыннарының, туганнарының, хезмәттәшләренең тирән кайгысын уртаклашам", – диелә Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз имзалаган кайгынамәдә.

# Дин әһелләренең гыйлемен күтәрү – халыкка хөрмәт күрсәтү

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

Безгә хәзер менә шушындый төпле, бер урында дини хезмәт куйган, дини багланышта торган хәзрәтләребезнең вәгазьләре кирәк. Монда безгә төрле хәзрәтләрне күрергә туры килде. Аларга олуг рәхмәтләребезне белдерәбез. Авыр һәм таләпчәнлек сорый торган олуг хезмәтләрендә Аллаһ сабырлык бирсен. Кешеләргә гыйлем бирү, аны аларның калебләренә сеңдерү – ул бик авыр вазифа", – дип нәзарәткә, хәзрәтләргә рәхмәтләрен җиткерде ул.

24 май көнне үзәктә агымдагы уку елына йомгак ясалды. Бирeдә оештырылган беренче уку елы, Чүпрәледән килгән авыл имамнарының сүзләреннән үк аңлашылганча, уңышлы үтте. Республика дин әһелләре өчен унар көнлек курсларда белемнәрне ныгыту, арттыру мөһим, әһәмиятле чарага әверелде.

Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз имамнарга сәламәтлек, илкөнгә тынычлык теләп, дипломнар тапшырды. "Быел курслар Буа имамнары белән башланып киткән иде, чүпрәлеләр белән тәмамланды. Диния нәзарәте, Россия ислам университеты көче, дәүләт ярдәме белән, Аллага шөкер, үзәктә ике йөзгә якын мулла белемнәрен ныгытты. Бу дөньяда муллаларга зур бер вазифа бирелгән – Аллаһы Тәгаләнең сүзен кешеләргә җиткерү. Коръән сүзләре имамнар аша адәм балаларына барып җитә. Монда укулар авылларда халык белән аралашып яшәүче имамнарыбызга шушы зур вазифаны тагын да ныграк тоярга ярдәм итәр", – диде ул.

Үзәк директоры Габдулла Гыйләҗев сүзләренә караганда, укулар авылларда җәй көне эш күп булу һәм шулай ук озакламый ураза башлану сәбәпле тукталып торачак, көздән исә белемнәрен күтәрү өчен авыл имамнарын янә шушы үзәккә җыя башлаячаклар.


**ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъват һәм мәгълүмат бүлеге**






## *Казанда намаз вакытлары*

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ясту намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 2.06.12 | 2:36 | 4:06 | 13:02 | 18:33 | 21:19 | 22:49 |
| Якшәмбе | 3.06.12 | 2:35 | 4:05 | 13:02 | 18:34 | 21:20 | 22:50 |
| Дүшәмбе | 4.06.12 | 2:34 | 4:04 | 13:02 | 18:35 | 21:21 | 22:51 |
| Сишәмбе | 5.06.12 | 2:33 | 4:03 | 13:02 | 18:35 | 21:22 | 22:52 |
| Чәршәмбе | 6.06.12 | 2:32 | 4:02 | 13:02 | 18:36 | 21:23 | 22:53 |
| Пәнҗешәмбе | 7.06.12 | 2:31 | 4:01 | 13:02 | 18:37 | 21:24 | 22:54 |
| Җомга | 8.06.12 | 2:31 | 4:01 | 13:02 | 18:37 | 21:25 | 22:55 |
| Шимбә | 9.06.12 | 2:30 | 4:00 | 13:02 | 18:38 | 21:26 | 22:56 |


**ООО «Ритуальные услуги»**
**Изготовление памятников и оград**

ул. К.Насыри, 17, мечеть Аль-Марджани,
ул. 2-я Армавирская мечеть Нур-эль-Ислам,
ул. Мусина, 10, мечеть Булгар,
ул. Чистопольская, 1, мечеть Казан Нуры,
Оренбургский тракт, 193, мечеть Гадель,
ул. Мавлютова, 48, мечеть Ризван,
ул. Фучика, 52, мечеть Хузейфа,

Понедельник - пятница -
с 9:00 до 18:00,
суббота - с 9:00 до 13:00.
**Тел.: 225-28-90, 293-25-61**

Основное производство находится на мусульманском кладбище при мечети Аль-Марджани на Мамадышском тракте.
Понедельник - с 9:00 до 13:00, со среды по воскресенье - с 9:00 до 18:00,
вторник - выходной.
**Тел.: 8-927-427-16-02, 293-45-93**

**На мусульманском кладбище захоронения ведутся по канонам Шариата.**
**Тел. 297-28-90**



**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №22 (139) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-536.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 31 май көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).


**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**